| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Совет Чукмарлинского сельского поселения Сармановского муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районы**<br>**Чукмарлы авыл җирлеге Советы** |

РЕШЕНИЕ КАРАР

№10 12 ноябрь 2020 ел

Чукмарлы авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 18 мартындагы 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 сентябрендәге 325-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Чукмарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Чукмарлы авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Чукмарлы авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 18 мартындагы 2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.салым түләүчеләр - оешмалар тарафыннан салым аванс белән, узган хисап чорыннан агымдагы салым чорының беренче, икенче һәм өченче кварталы узганнан соң, җир кишәрлегенең кадастр бәясе процентының тиешле салым ставкасының 1/4 күләмендә түләнә. Салым чоры нәтиҗәләре буенча түләнергә тиешле салым суммасы узган салым чорыннан соң килүче елның 1 мартыннан да соңга калмыйча түләнә».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) бастырып чыгарырга һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3.«Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин рәсми басылган көннән бер айдан да иртәрәк түгел».

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Чукмарлы авыл җирлеге
Советы Рәисе: И.Х.Хадиуллин